**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 27 » ____07____ 2021 № 234

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы
Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан
муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ
регламентларын раслау турында» 2021 ел, 18 февраль,
№62 Карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 27 июль, 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 ел, 2 ноябрь, №880 карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Электрон рәвештә социаль әһәмияткә ия дәүләт хезмәтләрен, дәүләт биреме (заказ) урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрен күрсәтүгә күчү буенча чаралар планын раслау турында» 2021 ел, 13 апрель, №242 карарына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2018 ел, 26 ноябрь, №651 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 ел, 18 февраль, №62 Карарына (2021 ел, 1 июль, №211 карарның кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарның 1.3, 1.4, 1.6, 1.7 пунктчаларын (Карарга 3, 4, 6, 7 нче кушымталар) төшереп калдырырга;
димәк, 1.5, 1.8-1.30 пунктчаларын (5, 8-30 нче Кушымталар) 1.3-1.26 пунктчалары (3-26 нчы Кушымталар) дип санарга.

Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 3 нче кушымтасын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

карарны түбәндәге редакциядә 1.27, 1.28 пунктчалары белән тулыландырырга:

«1.27. Сатулашулар уздырмыйча түләүгә җир кишәрлеген арендага, милек итеп бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (27 нче кушымта);

«1.28. Сатулашуларда җир кишәрлеген арендага, милек итеп бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (28 нче кушымта)».

- 27 нче кушымта белән әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә;
- 28 нче кушымта белән әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo. tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм мөлкәт белән идарә итү буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю. Зайцев